**2010-2015 еллар.**

2010 елда Рашитова Ф.Х. һәм Расулева Э.Р. югары категорияле ”җитәкче” булдылар. Аттестация вакытында эшенә югары бәя алуга ирештеләр.

2010 елда физика, информатика укытучысы Гиззатуллина Альбина Шамилевна Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының Мактаулы Грамотасы белән бүләкләнде.

2011 нче елдан мәктәпнең беренче сыйныфы 2 буын белем бирү стандартына күчте.

2012, 2013, 2014, 2016 нчы еллар Татарстан Республикасының “100 яхшы мәктәбе ” исеменә лаек булды.

2011 нче елда Үтәгән урта мәктәбе башлангыч мәктәпкә калу сәбәпле, аларның рус теле укытучысы Шайхутдинова Г.С., татар теле укытучысы Садыкова Г.Н. хезмәт юлларын Кадыбаш мәктәбендә дәвам иттеләр. Ә гомерләрен укытучылык эшенә багышлаган укытучыларыбыз Шаймарданова К.М., Фатхиева Д.К., Гарифуллина Г.С. лаеклы ялга киттеләр.

Шулай итеп, Кадыбаш, Касай, Үтәгән, Иске Эсләк авылы укучылары бер түбә астына тупланды. Көчле коллектив укытучылары тирән белем һәм тәрбия бирә. Шул уку елында ук мәктәп “100 яхшы мәктәп” исеменә лаек булды.

2013 нче елда уку елында Кадыбаш урта мәктәбе “Иң яхшы мәгариф учреждениесе” исеменә лаек булды.

2015 нче елны Девятерня мәктәбе тугызъеллыкка калу сәбәпле, 10 - 11 класс укучылары безнең мәктәптә белем алуларын дәвам итте. Узган гасырдагыча, Кадыбаш мәктәбе, әкрен-әкрен, Тугызбуй төбәгенең базы мәктәбенә әверелде.

2015 нче елда укыту эшләре буенча директор урынбасары Расулева Эльмира Раисовна “ Мәгарифтәге казанышлары өчен ” Күкрәк билгесе белән бүләкләнде.

2015 нче елда рус теле укытучысы Шайхутдинова Гүзәлия Сабирзяновна Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының Почет Грамотасы белән бүләкләнде.

Югары категорияле белгечләр: Заляев И.Н. (технология), Закиров Ш.М. (физкультура), Гиззатуллина А.Ш. (физика һәм информатика), Мулланурова З.Р.(математика), Расулева Э.Р. (татар теле һәм әдәбияты), Рашитова Ф.Х., Шайхутдинова Г.С. (рус теле һәм әдәбияты белгечләре).

Беренче категорияле белгечләр: Фатхиева Д.К., Ямалиева Т.Т. (башлангыч сыйныф укытучылары), Салихова А.К. (тарих, җәмгыять белеме), Камалиева В.И. (инглиз теле), Гиззатуллина Г.Н. (инглиз теле), Айдарова Л.Р. (химия, биология) Садыкова Г.А. (татар теле һәм әдәбияты), Рамазанова Г. (бакча тәрбиячесе), Закирова Г.Н (башлангыч класс укытучысы).

2015 елдан балалар бакчасы да Кадыбаш мәктәбенә кушылды. Бу елларда мәктәп түбәндәге белем бирү программаларын тормышка ашыра: -мәктәп гомумбелем бирү; башлангыч гоумбелем бирү; төп гомумбелем бирү; урта гомумбелем бирү.

Шуның 3 баскычы ФГОС нигезендә укытыла.

2016 нчы елда математика укытучысы Мулланурова Земфира Раисовна Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгының Почет Грамотасы белән бүләкләнде.